Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы карары

04.06.2017ел. № 56

Муниципаль районның аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтләрен җирлек башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирлекнең генераль планнарын, җирлектән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документацияне раслау, төзелешкә рөхсәтләр (Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), җирлектә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү, җирле нормативларны раслау җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектлары, муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлау һәм җирлек чикләрендә җир кишәрлекләрен алу, җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карау һәм мондый тикшерү барышында ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында киңәшләр бирү.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул ителгән очракта, Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты белән әлеге вәкаләтләрне әлеге карарның 1 пунктында тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советының 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге бюджеты турында карар проектын эшләү һәм карау өчен тәкъдим итү.

3. Әлеге карарны Б.Янгасала авылының Үзәк урамы 1 йорт; Шәпкә авылы, Клубная урамы, 14 йортта урнашкан мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районының
Яңасала авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы Яңасала авыл җирлеге Советы Рәисе
муниципаль район башлыгы И. Х. Шиһабеев